**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменения в статью 7**
**Закона Республики Татарстан «О государственной поддержке развития личных подсобных хозяйств на территории Республики Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
18 октября 2018 года

**Статья 1**

Внести в пункт 2 части 1 статьи 7 Закона Республики Татарстан от 12 января 2016 года № 3-ЗРТ «О государственной поддержке развития личных подсобных хозяйств на территории Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2016, № 1 – 2) изменение, изложив его в следующей редакции:

«2) субсидии гражданам, ведущим личное подсобное хозяйство, на возмещение части затрат на:
а) строительство мини-ферм молочного направления;
б) строительство теплиц;
в) приобретение товарного и племенного поголовья нетелей и первотелок;
г) приобретение товарного и племенного поголовья козоматок;
д) приобретение молодняка птиц (гусей, уток, индеек, цыплят-бройлеров);
е) услуги по искусственному осеменению коров;
ж) содержание кобыл старше трех лет;
з) проведение ветеринарных профилактических мероприятий по обслуживанию коров;
и) приобретение семенного и посадочного материала, материалов и оборудования для ведения овощеводства защищенного грунта, средств защиты растений;
к) приобретение саженцев плодовых и ягодных культур;».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ *
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
26 октября 2018 года
№ 75-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында” Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 18 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында” 2016 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 1 – 2), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“2) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга түбәндәгеләргә бирелгән чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр:

а) сөт юнәлешендәге мини-фермалар төзүгә;

б) теплицалар төзүгә;

в) товар өчен һәм нәселле таналар, бер бозаулаган сыерлар сатып алуга;

г) товар өчен һәм нәселле анабаш кәҗәләр сатып алуга;

д) кош-корт (казлар, үрдәкләр, күркәләр, бройлер чебешләр) бәбкәләре сатып алуга;

е) сыерларны ясалма орлыкландыру буенча хезмәт күрсәтүләргә;

ж) өч яшьтән зуррак бияләр асрауга;

з) сыерлар асрауда хезмәт күрсәтү буенча ветеринария-профилактика чаралары үткәрүгә;

и) сакланган туфракта яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен орлык һәм утырту материалы, материаллар һәм җайланмалар, үсемлекләрне саклау чаралары сатып алуга;

к) җиләк-җимеш культуралары үсентеләрен сатып алуга;”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казан, Кремль
2018 ел, 26 октябрь
№ 75-ТРЗ